**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
19.05.2020

**КАРАР**
№ 242

**Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 17 мартындагы 100 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый план-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алулар план-графикларын урнаштыру, мәгълүматны мондый план-графикларга һәм сатып алуларның план-графикларына кертү үзенчәлекләрен билгеләү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында»гы 2019 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының «Тәтеш муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында»гы 2017 елның 17 мартындагы 100 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Кушымтаның 13 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Сатып алу объектына кертелгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр санын һәм берәмлеген күрсәтеп, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контрактның башлангыч (максималь) бәясен яки контракт бәясен нигезләү (булганда)».

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Хисамовага йөкләргә.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**